# PAR AT

Çikterep par at, Qazanƣa tup-turь kittem qarap.
Captьra atlarnь kycer suqqalap ta, tartqalap.

Kic ide, şatlьq ʙelən nurlar cəcep aj jaltьrьj,
Iskən əkren çil ʙelən jafraq, aƣaclar qaltьrьj.

Hər taraf tьn. Uj miꞑa tik, əllə ni çьrlьj, uqi,
Nərsədənder kyz elengən həm təmam ʙasqan joqь.

Ber zaman acsam kyzem, ʙer tərle jap-jat qьr kyrəm,
Ah, ʙu nindi ajrьlu? ƣəmremdə ʙer tapqьr kyrəm.

Sav ʙul inde, xuş, ʙəxil ʙul, i minem torƣan çirem,
Min ʙolaj, şulaj itəm dip tərle uj qorƣan çirem.

Xuş ƣəmer itkən şəhər inde jьraqta qaldьƣьz,
Ah! Tanьş jortlar, təmam kyzdən də sez juƣaldьƣьz.

Ec poşa, jana jərək, xəsrət ecendə ujda min,
Icmasam iptəş tə juq ic, tik ikəv ʙez: uj da min.

Ah, gənahьm şomlьƣь, ʙu kycere ʙik tьn taƣьn,
Çьrlamьjdьr ʙer maturnьꞑ ʙaldaƣьn ja qalfaƣьn.

Əllə nərsəm juq keʙi, ʙer nərsə juq, ʙer nərsə kim,
Bar da ʙar, tik juq tuƣannar, min jətim, monda jətim.

Monda ʙar da jat miꞑa: Bu Minƣəli, Bikmulla kem?
Bikməxəmmət, Biktimer — ʙersen də ʙelmim, əllə kem!

Sezdən ajrьlьp, tuƣannar! Çajsьz, uꞑƣajsьz toru.
Bu toru, əjtergə məmkinder: qojaş, ajsьz toru.

Şundьj ujlar ʙerlə taştaj qattь kitte ʙaşlarьm,
Cişmə təsle ixtiarsьz aqtь kitte jəşlərem.

Ber tavьş kilde qolaqqa, jaꞑƣьradь ʙer zaman:
Tor, şəkert! Çittek Qazanƣa, aldьmьzda ʙit Qazan.

Bu tavьş ʙik actь kyꞑlem, şatlьƣьmnan çan jana,
„Əjdə cap, kycer, Qazanƣa! Atlarьꞑ qu na! na na!"

Əjtə irtənge namazƣa ʙik matur moꞑlь azan,
I Qazan! Dərtle Qazan! Moꞑlь Qazan! Nurlь Qazan.

Mondadьr ʙeznez ʙaʙajlar tyrlərе pocmaqlarь.
Mondadьr dərt e kyꞑelneꞑ xurlarь, oçmaxlarь.

Monda xikmət, məƣrifət həm monda ƣirᶜan, monda nur!
Monda minem neckə ʙilem, çənnətem həm monda xur!